# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине составын һәм аны билгеләү тәртибен билгели.

1 статья. **Куллану кәрзине төшенчәсе**

Куллану кәрзине - кеше сәламәтлеген саклау һәм аның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле индивидуаль һәм гаиләдә гомуми файдаланыла торган туклану продуктларының, азык-төлек булмаган товарларның, шулай ук хезмәт күрсәтүләрнең минималь җыелмасы.

2 статья. **Татарстан Республикасында куллану кәрзиненең составы**

Татарстан Республикасында куллану кәрзиненә түбәндәгеләр керә:

1. ТУКЛАНУ ПРОДУКТЛАРЫ

| Продуктларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Куллану күләме (бер кешегә елына уртача) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | эшкә яраклы халык | пенсионерлар | балалар |
| Икмәк продуктлары (икмәк һәм онга күчереп исәпләнгән макарон әйберләре, он, ярмалар, кузаклылар) | кг | 151,306 | 118,128 | 97,758 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Бәрәнге | кг | 115,300 | 95,000 | 115,285 |
| Яшелчә һәм бакча әйберләре | кг | 101,410 | 80,800 | 111,498 |
| Яңа өлгергән җиләк-җимеш | кг | 16,640 | 13,600 | 41,130 |
| Шикәр һәм шикәргә күчереп исәпләнгән кондитер әйберләре | кг | 20,357 | 18,847 | 24,018 |
| Ит продуктлары | кг | 32,933 | 22,700 | 28,422 |
| Балык продуктлары | кг | 8,000 | 6,000 | 11,257 |
| Сөт һәм сөткә күчереп исәпләнгән сөт продуктлары | кг | 210,813 | 198,300 | 296,000 |
| Йомырка | данә | 165,300 | 90,000 | 170,190 |
| Үсемлек мае, маргарин һәм башка майлар | кг | 13,285 | 9,000 | 10,365 |
| Башка продуктлар (тоз, чәй, тәмләткечләр) | кг | 4,880 | 4,150 | 3,659 |

2. АЗЫК-ТӨЛЕК БУЛМАГАН ТОВАРЛАР

| Товарлар исеме | Үлчәү берәмлеге/ тузу вакыты | Куллану күләме (бер кешегә елына уртача) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | эшкә яраклы халык | пенсионерлар | балалар |
| Өс киеме (пальто) төркеме | данә/ел | 3,0/7,6 | 3,0/8,8 | 3,0/2,5 |
| Өс киеме (костюм-күлмәк) төркеме | данә/ел | 8,5/4,4 | 7,7/4,8 | 11,3/1,9 |
| Эчке кием | данә/ел | 9,5/2,5 | 9,8/2,9 | 11,0/1,9 |
| Оек-оекбаш әйберләре | пар/ел | 6,5/1,5 | 4,3/2,0 | 6,3/1,6 |
| Баш киемнәре һәм галантерея әйберләре | данә/ел | 5,0/5,1 | 4,0/5,6 | 4,3/3,0 |
| Аяк киеме | пар/ел | 6,0/3,4 | 6,7/3,8 | 6,7/1,8 |
| Мәктәп өчен кирәкле язу-сызу товарлары | данә/ел | 3,0/1,0 | 3,0/1,0 | 27,6/0,7 |
| Урын-җир әйберләре | данә/ел | 14,5/7,0 | 14,5/7,0 | 14,5/7,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мәдәни-көнкүреш һәм хуҗалык билгеләнешендәге товарлар | данә/ел | 19,2/10,5 | 19,2/10,5 | 19,2/10,5 |
| Беренче кирәкле әйберләр, санитария әйберләре һәм дарулар | азык-төлек булмаган товарларга айлык чыгымнарның гомуми күләменнән 10 % | | | |

3. ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЛӘР

| Хезмәт күрсәтүләрнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Куллану күләме (бер кешегә елына уртача) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | эшкә яраклы халык | пенсионерлар | балалар |
| Торак | гомуми мәйданы, кв.м | 18,00 | 18,00 | 18,00 |
| Үзәктән җылыту | елына, Гкал | 5,40 | 5,40 | 5,40 |
| Салкын һәм җылы су белән тәэмин итү һәм су бүлеп тарату | тәүлегенә, литр | 250,00 | 250,00 | 250,00 |
| Газ белән тәэмин итү | аена, куб/м | 10,00 | 10,00 | 10,00 |
| Энергия белән тәэмин итү | аена, кВт/сәг. | 25,00 | 25,00 | 25,00 |
| Транспорт хезмәтләре күрсәтү | юл йөрү, елына | 620 | - | 404 |
| Хезмәт күрсәтүләрнең башка төрләре | хезмәт күрсәтү чыгымнарының айлык гомуми күләменнән 15 % | | | |

3 статья. **Татарстан Республикасында куллану кәрзинен билгеләү тәртибе**

Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре (эшкә яраклы халык, пенсионерлар, балалар) өчен куллану кәрзине, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган тәртиптә үткәрелүче экспертиза бәяләмәсе булганда, кимендә биш елга бер мәртәбә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

4 статья. **Татарстан Республикасында куллану кәрзиненең хакын бәяләүне билгеләү тәртибе**

Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине хакының бәясе Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Статистика буенча дәүләт комитеты тәкъдиме буенча квартал саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана һәм ул рәсми басылып чыгарга тиеш.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе турында**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2002 елның 28 гыйнвары
№ I332